ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская, д.16в,
423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 16в йорт,
423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№5 2019 елның 11 ноябре

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 22 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 45А нче йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Иске Урыссу авылы гражданнары җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Иске Урыссу авылында юлларны кардан чистарту;
- Иске Урыссу авылында агачларны кисү, зират ихатасын алыштыру (сатып алу, килешү буенча эшләргә түләү) ;
- Иске Урыссу авылының Рокоссовский, Чапаев, Октябрь урамнарындагы юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү).

« ӘЙЕ» “ЮК".

3. Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында www.yutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

"Урыссу авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
Башлыгы вазифаларын башкаручы Ф.Г. Әминова